

Билгесез солдат коне - Россия тарихында чагыштырмача яна истәлекле дата, ел саен – 3 декабрьдә билгеләп vтелә. Бу кон сугыш хәрәкәтләрендә һәлак булган һәм исемнәре билгесез булган Совет һәм Россия сугышчыларынын хәтерен, хәрби батырлыгын һәм vлемсез батырлыгын мәнгеләштерvгә юнәлдерелгән.  Россиябезнен торле почмакларында бу конне билгеләп, торле-торле чара-лар vтте, шул исәптән Мордовиядә дә. Бар җәмгыятчелек белән бергә укучыларыбыз-укытучыларыбыз да, ис-тәлекләрне янартып, укучыларда Ватанны саклаучыларга карата хормәт, кырыс елларда Ватан азатлыгын һәм бәйсезлеген саклаган vз халкы очен горурлык хисе тәрбияләv, истәлекле дата турында белемнәрне формалаштыру максатыннан, «Исемен синен билгесез, батырлыгын vлемсез» дигән чаралар кон тәртибендә булган. Мәсәлән, Темников районы Аксел урта мәктәбе обелисклары янында Хәтер дәресе vткәргәннәр. Укучылар һәм укытучылар, vз гомерләрен куркыныч астына куеп Ватанны саклаган барлык билгесез солдатларны, бер минут тынлык белән искә алганнар. Безнен тыныч кvк йозе очен рәхмәт йозеннән, балалар һәм олкәннәр һәлак булган авылдаш сугышчылары һәйкәленә кызыл канәфер-гвоздикалар салганнар.



Шулай ук Рузаевка районы Татар Пешлә авылында бу кон истәлекле vткән. Авыл администрациясе житәкчесе Ринат Дәvлюк улы Шабаев, хезмәткәрләре белән бергә, хәбәрсез югалган авылдашларын искә алып, Боек Ватан сугышында вафат булган авылдашлары һәйкәленә чәчәкләр салганнар. Мәктәпләрендә, Мәдәният йортларында, китапханәләрендә бу кон ачык дәресләр, лекцияләр, тантаналы әдәби-музыкаль композицияләр һәм акцияләр vткәргәннәр.

Ләмберә районы-бызнын шулай ук торле почмакларында торле чаралар vтте. Мәсәлән, Билгесез солдат конен искә алып, Татар Тавла авылы администрациясе хезмәткәрләре, Татар Тавласы авылы топ мәктәбе укучылары, укытучылары белән бергә, митинг vткәргәннәр.

Ватанны саклаучы-ларнын исемнәрен белмәсәк тә, безнен бурыч – аларны истә тоту һәм

батырлыкларына киләчәк буында хөрмәт тәрбияләv.  Беркем дә, бернәрсә дә онытылмады!